# СОҢГЫ КЫҢГЫРАУ

Кояш балкып карый безгә
Мәктәптә бүген бәйрәм
Һәркем кулларына тоткан
Чәчәкләр бәйләм-бәйләм

**Кушымта:**
Чынлый да чынлый кыңгырау
Бигрәк матур чынлавы
Җырлап барсын иде шулай
Гомеребез (гомерегез) юллары

Әллә җибәрәсе килми
Чынлый кыңгырау, чынлый
Мәктәптә узган вакытлар
Хәтердән бердә чыкмый

Мәктәп тәрзәләре нигә
Калалар моңсу карап
Саумы мәктәп дия дия
Килербез сиңа кабат